Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пунктында

ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

“08” ноябрь 2024 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Иске Өҗем торак пунктында халык җыены

КАРАР КЫЛДЫ:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районың Өҗем авыл җирлеге территориясендә 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән, 18 яшькә җиткән, тавыш бирү хокукына ия булган, , көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, һәр кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Өҗем торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү ("Әлия чишмәсе" һәм "Ат чишмәсе"чишмәләрен төзекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)) – мәсьәләсен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлегенең Иске Өҗем авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Өҗем авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.